МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2020 г.Казань № 515

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 11 августында 6811 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне, расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф.Валиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 14 июлендәге 515 номерлы боерыгы белән расланган

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 395, 28.11.2016 ел № 668, 08.06.2017 ел № 349, 15.05.2018 ел № 367, 24.09.2018 ел № 897, 21.02.2019 ел № 129, 19.04.2019 ел № 285, 10.09.2019 ел № 688, 14.11.2019 ел № 1007, 05.02.2020 ел № 65, 08.05.2020 ел № 289 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә

урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Нигезләмәнең» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба - Нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)»;

2.14 пунктындагы «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары

тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе (алга таба – 880 номерлы тәртип)» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы бернче абзацта «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (07.06.2016 ел № 317, 07.09.2016 ел № 513, 08.06.2017 ел № 349, 23.05.2018 ел № 392, 24.09.2018 ел № 897, 04.02.2019 ел № 77, 14.08.2019 ел № 622, 14.11.2019 ел № 1009, 08.05.2020 ел № 289 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 2015 елның 26 гыйнварындагы 47 номерлы «Абонентка даими файдалануга тапшырылган теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү буенча чыгымнарны каплауга субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Абонентка даими файдалануга тапшырылган теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү буенча чыгымнарны каплауга субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба - Регламент):

1 бүлектә:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Нигезләмәнең» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба - Нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «63-ЗРТ номерлы Закон» сүзләрен «2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 63-ЗРТ номерлы Закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе (алга таба – 880 номерлы тәртип)» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 401, 08.06.2017 ел № 349, 18.05.2018 ел № 383, 24.09.2018 ел № 897, 04.02.2019 ел № 77, 07.08.2019 ел № 598, 14.11.2019 ел № 1008, 08.05.2020 ел № 289 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 2015 елның 26 гыйнварындагы 46 номерлы «Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы

белән расланган Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «542 номерлы Нигезләмәнең» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба – 542 номерлы Нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Нигезләмә» сүзен «542 номерлы Нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «63-ЗРТ номерлы Закон» сүзләрен «2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 63-ЗРТ номерлы Закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга;

2.14 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «880 номерлы тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе (алга таба – 880 номерлы тәртип)» сүзләренә алмаштырырга.